Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге Советы Карары

22 апрель 2019 ел № 87

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 76 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 76 номерлы «физик затлар милкенә салым турында» гы карарына (2015 елның 3 июнендәге 101 номерлы, 2015 елның 19 октябрендәге 5 номерлы, 2018 елның 2 июлендәге 70 номерлы, 2019 елнын 9 мартындагы 84 номерлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 4.1 пунктындагы 6 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар рәтенә керә:

- йорт кенәгәсеннән өземтә;

- әлеге салым буенча салым түләүче дип танылган физик затның шәхесен раслаучы документ;

- аның исеменә бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы яки ул ата-ана (уллыкка алучы) булган балаларның туу турындагы таныклыгы.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл башлыгы Ф.Т. Мухаметгалиев